ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«30» октябрь 2025 ел** **№ 1040**

**Яңа Кенәр авылыннан тыш, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә салкын су белән тәэмин итүнең һәм су түгүнең үзәкләштерелгән системасы өчен гарантияле оешманы билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә өзлексез су белән тәэмин итүне һәм су агызуны оештыру максатларында, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 11, 12 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Арча муниципаль районы Водоканалы” ҖЧҖен (ОГРН 1251600043200, ИНН 1685023230) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә, Яңа Кенәр авылыннан тыш, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу системасы өчен гарантияле оешма итеп билгеләргә.

2. Гарантияле оешма “Арча муниципаль районы водоканалы” ҖЧҖ тарафыннан файдаланыла торган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә билгеләнгән тәртиптә тоташтырылган абонентларга салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны тәэмин итәргә тиеш.

3. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, Яңа Кенәр авылыннан тыш, Арча муниципаль районында су белән тәэмин итү һәм су агызу өчен билгеләнгән коммуналь хуҗалык объектларына инвентаризация үткәрергә һәм эксплуатацияләү һәм карап тоту өчен «Арча муниципаль районы Водоканалы» ҖЧҖенә тапшырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты Аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.А.Галимуллин